РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

СОВЕТ ШЕМОРДАНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
0, Республика Татарстан, Сабинский
район,
с. Шемордан, ул. Лермонтова, 2
тел. (84362) 2-27-05

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ШӘМӘРДӘН
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422050, Татарстан Республикасы,
Саба районы,
Шәмәрдән авылы, Лермонтов
урам, 2 йорт
тел. (84362) 2-27-05

e-mail: Shmd.Sab@tatar.ru

---

РЕШЕНИЕ
13.11.2024

КАРАР
№ 25

Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге Советының 28.04.2018 № 10 «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына һәм муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында Нигезләмә» карарына үзгәрешләр кертү хакында

Җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең социаль гарантияләрен тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 25.09.2024 елгы №829 "Даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, рәисләрнең, рәис урынбасарларының, муниципаль берәмлекләрнең тикшерү-исәп аудиторларының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында" 28.03.2018 ел №182 нче карары нигезендә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге Советы

Карар кылды:

1. Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге Советының 28.04.2018 ел, № 10 карары белән расланган «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының һәм муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмә» гә (09.11.2020 ел, №11, 21.10.2022 ел, №19, 19.12.2022 №25 карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгече вазыйфаи окладын 13 990 сум күләмендә расларга»;

1.2. Карар өчен 1 нче кушымтаны әлеге карарның 1 нче кушымтасы буенча яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге җирле үзидарә органнарына әлеге карар белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып, 2025 елның 1 гыйнварыннан гамәлгә кергән яңа штат расписаниеләрен расларга.

3. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тиешле финанс елына җирле бюджетларда каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга.

Авыл җирлеге башлыгы　　　　　　　　　　　　　　　　А.К.Вәлиев

Кушымта №1

Татарстан Республикасы Саба муниципаль
Районы Шәмәрдән авыл җирлеге Советының
13.11.2024 ел № 25 карары

Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге башлыгы, депутатлар, Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы сайланулы вазыйфаи затларына акчалата бүләк күләме

| Вазыйфалар исемнәре | Акчалата бүләк күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Авыл җирлеге башлыгы | 22 810 |
| Депутатлар | 13 990 |
| Сайланулы вазыйфаи затлар | 13 990 |